| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК** |
| 19.12.2014 | № 01-02/599 |

Казан ш.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар Реестрын раслау турында» 2014 елның 4 февралендәге 01-02/9 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Аерым муниципаль берәмлекләрнең үзгәртелүе һәм чикләре үзгәрү турында Татарстан Республикасы законнары кабул ителүенә бәйле рәвештә,

БОЕРАМ:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар Реестрын раслау турында» 2014 елның 4 февралендәге 01-02/9 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар Реестрына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

7 нче бүлекне түбәндәге редакцияләүдә күрсәтеп бирергә:

« 7 бүлек. Татарстан Республикасы административ-территориаль төзелешенең 2014 елгы үзгәрешләре исемлеге

| № п/п | Үзгәрешнең эчтәлеге | Үзгәрешләр кертелүгә нигез булган хокук актының реквизитлары | Үзгәрешләр кертелүгә нигез булган хокук актының үз көченә керү датасы | Реестрдагы үзгәреш турында язылу датасы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кама Тамагы муниципаль районының Теньки авыл җирлеге составына кергән Ясная Звезда авылы территориясенең Югары Ослан районы муниципаль районының Майдан авыл җирлеге территориясенә кертелүе | “Аерым муниципаль берәмлекләрнең территория чикләре үзгәртелү һәм «Кама Тамагы муниципаль районы» һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр» муниципаль берәмлегенең территория чикләрен билгеләү һәм статусы турында” һәм «Югары Ослан муниципаль районы» һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр» муниципаль берәмлегенең территория чикләрен билгеләү һәм статусы турында” 2014 елның 13 декабрендәге 114-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы | 16.12.2014 | 19.12.2014 |
| 2. | Югары Ослан районы Иннополис поселогының Иннополис шәһәренә үзгәртелүе һәм «Введенско-Слободское авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бүленү юлы белән үзгәртелеп, аның нигезендә ике муниципаль берәмлек: “Иннополис шәһәре” һәм | «Югары Ослан районы Иннополис поселогының үзгәртелүе, аерым муниципаль берәмлекләр территориясендәге үзгәрешләр һәм Югары Ослан муниципаль районы Введено-Слободское авыл җирлегенең үзгәртелүе, шулай ук, «Югары Ослан муниципаль районы» һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр» муниципаль | 16.12.2014 | 19.12.2014» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | “Введено-Слободское авыл җирлеге” барлыкка килү | берәмлегенең территория чикләрен билгеләү һәм статусы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелү турында 2014 елның 13 декабрендәге 115-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы | | |

Министр Л.Ю.Глухова